КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 13 декабрь г.Казань № 1225

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хуҗалык исәбе документларын раслау турында» 2006 ел, 29 ноябрь, 575 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының җирле органнары тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалыкларның хуҗалык исәбен алып бару буенча методик тәкъдимнамәләргә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хуҗалык исәбе документларын раслау турында» 2006 ел, 29 ноябрь, 575 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының җирле органнары тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалыкларның хуҗалык исәбен алып бару буенча методик тәкъдимнамәләргә, 38 пунктның җиденче абзацында «транспорт предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары, урман, су, балык, аучылык хуҗалыгы» сүзләрен – «икътисадның аерым тармаклары оешмалары, шул исәптән транспорт оешмалары, урман комплексы, су, балык, аучылык хуҗалыклары, дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли парклар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы федераль дәүләт бюджет учреждениеләре» сүзләренә, «кагыйдә буларак, вакытлыча файдалануга» сүзләрен «түләүсез файдалануга» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин